РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

13 февраль 2015 ел № 6-45

**«Буа муниципаль районы Советының 2014 елның 16 декабрендәге 2-43 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану турында»**

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясындагы 1 пунктына ярашлы рәвештә, Буа шәһәр Прокуратурасының 2015 елның 12 гыйнварындагы 02-08-02 номерлы тәкъдимен карап чыгып, Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» МКУсен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен сатып алулар өлкәсендә контроль орган итеп билгеләү турында» Буа муниципаль районы Советының 2014 елның 16 декабрендәге 2-43 номерлы карарын;

-Буа муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 16 декабрендәге 3-43 номерлы карарын.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Буа муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары И.Ф. Еремеевка йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы рәисе А.К. Айзетуллов